**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай**
**муниципаль районы**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево,
423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592)
7-20-31
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай
шәһәре, 423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592) 7-
20-31
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«__02__» ___12_____ 2024 ел.** **№ __253__**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Чалпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлауларны үткәрүне билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 31 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Азнакай районы Советының 2018 елның 22 августындагы 203-30 номерлы карары белән расланган «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Чалпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлауларны үткәрүне (алга таба - гавами тыңлаулар) билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны оештыручы итеп - Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты турында фикер алышу буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем составын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Гавами тыңлауларны оештыручыга җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә гавами тыңлауларны оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

5. Гавами тыңлауларны уздыру чорын - кызыксынучы затларга гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр билгеләргә. Гавами тыңлауларны уздыру вакыты бер айдан да артык була алмый.

6. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлегенә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясы нигезендә иҗтимагый фикер алышулар башлану турында хәбәрнамә әзерләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча»: http://aznakaevo.tatar.ru һәм шулай ук «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык М.З. Шәйдуллин

Азнакай муниципаль районы Башлыгы
карарына кушымта
« ____»________ 2024 №_____

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты турында фикер алышу буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем составы

*Зшче төркем рәисе:*

| | |
|---|---|
| Шәмсетдинов А.Х. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |

*Эшче төркем секретаре:*

| | |
|---|---|
| Әюпова Р.Р. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече (килешү буенча) |

*Эшче төркем эгъзалары:*

| | |
|---|---|
| Мөхәмәтшин А.М. | Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Башлыгы (килешү буенча) |
| Гәрәев А.С. | Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Советы депутаты (килешү буенча) |
| Сабирҗанов Н.Г. | Азнакай районы Советы авыл җирлекләре белән эшләү секторы мөдире |